**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Пробуждение авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 14 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Пробуждение авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1)2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Пробуждение авыл җирлеге территориясендә I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.

1. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Пробуждение торак пунктында Беларус-82,1 тракторын тоту (водитель хезмәтләренә түләү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

-Пробуждение торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

- Пробуждение торак пунктынын Татарстан урамы юлын ремонт (таш белән капланган чокырлы ремонт, вак таш сатып алу, ташу, таш салу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

2) урам яктырту җайланмасы:

Пробуждение торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

3) ремонт, коймалар тоту, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зират өс төзү өчен материаллар сатып алу һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

6) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын урнаштыру);

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р.Нуртдинов